**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 28 август № 630

г. Казань

«Тәтеш педагогика көллияте» һөнәри белем бирүче дәүләт автоном учреждениесе исемен «Тәтеш дәүләт гражданнарны яклау көллияте» һөнәри белем бирүче дәүләт автоном учреждениесенә үзгәртү турында

Гадәттән тыш хәлләрдә гражданнар оборонасы һәм аларны яклау өлкәсендә квалификацияле кадрларны өзлексез һөнәри әзерләүне оештыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Тәтеш педагогика көллияте» һөнәри белем бирүче дәүләт автоном учреждениесе исемен «Тәтеш дәүләт гражданнарны яклау көллияте» һөнәри белем бирүче дәүләт автоном учреждениесенә (алга таба – Тәтеш дәүләт гражданнарны яклау көллияте) үзгәртү турындагы тәкъдимнәрен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

Тәтеш дәүләт гражданнарны яклау көллиятен гамәлгә куючы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкарырга;

Тәтеш дәүләт гражданнарны яклау көллиятендә укучыларны әзерләү алып барылачак белгечлекләр исемлеген билгеләргә;

60 көн эчендә түбәндәгеләргә тиешле үзгәрешләр кертергә:

«Тәтеш педагогика көллияте» һөнәри белем бирүче дәүләт автоном учреждениесе уставына;

Тәтеш дәүләт гражданнарны яклау көллиятенә дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләре башкаруга) гамәлгә куючының дәүләт йөкләмәсенә.

3. Гамәлгә куючының дәүләт йөкләмәсен үтәвен финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм аның үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2010 ел, 29 апрель, 308 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә, Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында тиешле финанс елына һәм план чорына әлеге максатларга күздә тотылган акча чикләрендә гамәлгә ашырыла, дип билгеләргә.

4. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, «Тәтеш педагогика көллияте» һөнәри белем бирүче дәүләт автоном учреждениесе уставына үзгәрешләр кертелгәннән һәм аларны раслаганнан соң бер ай эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга урта звено белгечләрен әзерләү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм Татарстан Республикасының дәүләт һөнәр белеме бирү оешмалары мөлкәтен карап тотуга нормативлар чыгымнарын раслау турында» 2014 ел, 29 октябрь, 807 нче карарына әлеге карарның 1 нче пунктына туры китерү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында карар проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\630.doc